Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Советының кырыкынчы утырышы

Богородский авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

29 июль, 2024 ел № 106

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башлыгы һәм муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары, шулай ук «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы итеп билгеләп кую турында» 2024 елның 10 июлендәге 103 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Советы карары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлеге башлыгы һәм муниципаль хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү турында» 2021 елның 9 апрелендәге 23 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге советы карарына (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге советының 2022 елның 10 октябрендәге 54, 2022 елның 29 декабрендәге 64, 2024 елның 29 маендагы 100 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 нче кушымтада таблицада «башкарма комитет җитәкчесе» графасындагы күрсәткечләр белән «-» «Коэффициент» баганасын «1,86» мәгънәсенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Богородский авыл җирлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар 2024 елның 11 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге башлыгы урынбасары В.М. Барышев